ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 11 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында гражданнарның эконом класслы торак сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2012 елның 28 декабрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында “җирлекләрнең һәм шәһәр округларының”, “(алга таба – җирле үзидарәнең вәкаләтле органы)” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 3 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1. Шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы:”;

3) 6 статьяда:
а) 6 өлештә “җирлек башлыгы, шәһәр округы башлыгы” сүзләрен “шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы” сүзләренә алмаштырырга;
б) 7 өлештә “Җирлек башлыгы, шәһәр округы башлыгы” сүзләрен “Шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы”сүзләренә алмаштырырга;
в) 8 өлештә:

беренче абзацта “Җирлек башлыгы, шәһәр округы башлыгы” сүзләрен “Шәһәр җирлеге башлыгы, муниципаль район башлыгы (авыл җирлекләре территорияләренә карата), шәһәр округы башлыгы”сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $1^{1}$ пункт өстәргә:

“$1^{1}$) мондый исемлекләргә үзгәрешләр кертү шартнамә нигезендә төзелә торган эконом класслы торакның гомуми санын арттыруга китермәсә, гражданнан аны мондый исемлеккә кертү турында гариза алу;”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 26 марты
№ 21-ТРЗ